**2020 елда Казан шәһәрендә Бәйсез дәүләтләр бердәмлеге (БДБ) илләре уеннары**

**<u>Рәсми сайт</u> I БДБ илләре уеннары, 2020 елның 20-27 августы Казан, Россия** https://ciskazan2020.com/tt

**Уеннар**

Уеннар турында

Символика

**Кабул итүче як**

Россия

Казан

**Кушылыгыз**

Аккредитация

Волонтерлар

Партнерлык программасы

**<u>Рәсми Татарстан</u>** http://tatarstan.ru/tat/index.htm/news/1659686.htm

**БДБ илләре уеннары Татарстанда 2020 елдагы иң мөһим спорт вакыйгаларының берсе булачак**

20-27 август көннәрендә Казанда БДБ илләре уеннары узачак. БДБ илләре уеннары Татарстанда 2020 елдагы иң мөһим спорт вакыйгаларының берсе булачак. Бүген бу хакта ТР Министрлар Кабинетында узган брифингта Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе генераль директоры Азат Кадыйров сөйләде.

“Хәзер без ярышларга актив әзерлекне башладык. Казанда әзер спорт һәм шәһәр инфраструктурасының булуы БДБ илләре уеннарын объектлар төзелешенә һәм реконструкцияләүгә өстәмә чыгымнарсыз уздырырга мөмкинлек бирәчәк”, - дип ассызыклады спикер.

Искә төшерәбез, БДБ илләре уеннарында Азәрбайҗан, Әрмәнстан, Беларусь, Казахстан, Кыргызстан, Молдова, Россия, Таҗикстан, Төркмәнстан, Үзбәкстан, Украинадан 2500 спортчы катнашачак. 230 комплект медаль уйнату планлаштырыла. Ярышлар спортның 21 төре буенча узачак...

**Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе**

https://tat.dspkazan.com/projects/current/ciskazan2020/


**Дирекция**

- Дирекция турында
- Җитәкчелек
- Партнерлык программасы
- Kazan Volunteers командасы

**Проектлар**

- Агымдагы
- Гамәлгә ашырылган

**Казан**

- Казан турында
- Ничек килеп җитәргә
- Шәһәр транспорты
- Истәлекле урыннар
- Объектлар

**МЕДИА**

- Яңалыклар
- Фото
- Видео
- ММЧ вәкилләренә

**БДБ илләре уеннары 2020**



2020 елгы I нче БДБ илләре уеннарының рәсми сайты

20-27 август көннәрендә Казан 2020 елда Татарстанда үтәчәк иң мөһим спорт ярышларының берсе – БДБ илләре уеннарын кабул итәчәк. Ачылу һәм ябылу тантаналары 20 һәм 27 августта “Баскет-холл”да узачак. Якынча 280 медаль комплекты уйнату планлаштырыла.

**Уеннар хакында**

БДБ илләре уеннарын үткәрүне Россия Федерациясе тәкъдим итте. Тәкъдим 2018 елның 28 сентябрендә Дүшәнбе шәһәрендә узган БДБ илләре башлыклары советы утырышында хупланылды.

Ярышларда катнашу өчен Казанга Әзербайҗан, Әрмәнстан, Беларусь, Казахстан, Кыргызстан, Молдова, Таҗикстан, Төркмәнстан, Үзбәкстан һәм Украина командалары чакырыла – барлыгы 14-23 яшьлек якынча 2500 спортчы, шулай ук Берлекнең 11 иленнән меңгә якын рәсми зат.

Ярышлар спортның 21 төре буенча узачак: баскетбол (3х3), бокс, волейбол (пляжныкы), өстәл теннисы, нәфис гимнастика, су полосы, дзюдо, бадминтон, йөзү, ирекле һәм грек-рим көрәше, самбо, фехтование, футзал, билбау көрәше һәм татарча көрәш, каратэ, бию спорты, армрестлинг, мас-рестлинг, гер спорты, тай боксы, шахмат.

Ярышлар үткәрү өчен 16 объект җәлеп ителәчәк: Идел буе физик культура, спорт һәм туризм академиясе уку-лаборатория комплексының спорт залы, Казан теннис академиясе, Бадминтон үзәге, “Буревестник” бассейны, “Зилант” спорт комплексы, Гимнастика үзәге, Су спорт төрләре сарае, Пляж спорты төрләре үзәге, “Ак Барс” көрәш сарае, “Олимп” спорт комплексы

һәм “Олимп” бассейнындагы спорт залы, Бокс һәм өстәл теннисы үзәге, “Мирас” спорт комплексы...

**<u>Татарстан Республикасы спорт министрлыгы</u>**

http://minsport.tatarstan.ru/tat/index.htm/news/1682856.htm

**БДБ илләренең беренче уеннарының волонтерлык кампаниясе башланды**



Оештыручылар 20дән артык функциональ юнәлеш буенча Россиядән һәм башка илләрдән 2 мең волонтерны җәлеп итәргә планлаштыра. Аларның күбесе (1750) Татарстан Республикасы исеменнән чыгыш ясаячак. Волонтерлык үзәкләре ассоциациясе белән партнерлык ярдәмендә 100 ирекле ярдәмче Россия төбәкләреннән, тагын 100 – БДБ илләреннән киләчәк.

«БДБ илләре уеннары безнең республикада спорт елының төп вакыйгасы булачак. Бу бик масштаблы чара: ярышлар 21 спорт төре буенча узачак. Әлбәттә, безгә ирекле ярдәм кирәк булачак. Без уеннар программасына кушылырга, волонтерлык программасында катнашырга теләүчеләрне чакырабыз», - ди спорт һәм социаль проектлар дирекциясе " КАО генераль директоры урынбасары Александр Карпов.

Исегезгә төшерәбез, БДБ илләре уеннары Казанда 20-27 август көннәрендә узачак һәм ТАССРның 100 еллыгын бәйрәм итүгә багышланачак. Казанда узачак ярышларда катнашу өчен Әзербайҗан, Әрмәнстан, Белоруссия, Казахстан, Кыргызстан, Молдова, Таҗикстан, Төркмәнстан, Үзбәкстан һәм Украина командалары – 14-23 яшьлек барлыгы 2500 спортчы, шулай ук БДБның 11 иленнән 1000гә якын рәсми зат җыелачак. Уеннар БДБ

катнашучылары булмаган дәүләтләр командаларының катнашуы өчен ачык. 245 комплект медаль уйнату планлаштырыла...

**Безнең мирас** http://beznenmiras.ru/bdb-illare-uennary/

**Көрәш БДБ илләре Уеннары программасына кергән**

2020 елның августында Казанда I БДБ илләре Уеннары узачак. Бу хакта кичә Россия Хөкүмәте утырышында билгеле булды.
Әлеге Уеннарны уздыру тәкъдиме белән Россия спорт министрлыгы чыккач, ил Президенты Владимир Путин тиешле проект әзерләү бурычын куйган. Ярышлар Олимпия уеннары узачак елда үтә, шуның өстенә ТАССРның 100 еллыгын билгеләп үтү чорында оештырылачак. Уеннарны уздыру урыны итеп Казанның сайлануы очраклы түгел, чөнки бездә теләсә нинди спорт ярышларын югары дәрәҗәдә үткәрү мөмкинлеге бар...

**Ватаным Татарстан** https://vatantat.ru/2020/01/14493/

**Казанда Бәйсез Дәүләтләр Бергәлеге уеннарына узачак**

Август ае кабат кызу булырга охшап тора. Казан 2020 елның төп вакыйгасына – Бәйсез Дәүләтләр Бергәлеге уеннарына әзерләнә. Оештыручылар әйтүенчә, ярышны бүгеннән үк башлап җибәрергә мөмкин. Моның өчен әллә ни корасы-төзисе дә юк. Ярышлар Олимпия уеннары елында, өстәвенә ТАССРның 100 еллыгын бәйрәм итү кысасында узачак. Тарихта беренче мәртәбә үткәрелә торган ярышны уздыру урыны итеп ни өчен Казанны сайлаганнар? Татарстан спорт министрының беренче урынбасары Хәлил Шәйхетдинов аңлатуынча, безнең тәҗрибәгә һәм оештыру сәләтенә ышаныч зур. Уеннарны үткәрү турында 2018 елны узган БДБ илләре советында уйлана башлыйлар. Соңрак исә нигезләмәсен булдыралар.
– Беренчедән, бу сайлауда Казанда Универсиада, су спорты төрләре буенча ярышлар узу да тәэсир иткәндер. Казанга гына түгел, республиканың башка шәһәрләренә дә ярышлар үткәрү мөмкинлеген бирәләр. Татарстан әзер,

өстәмә чыгымнар кирәкми, корылмалар бар. Әлеге уеннар халыкларны берләштерү өчен бер дигән массакүләм чара булачак, – диде ул. Шулай итеп Әзәрбайҗан, Әрмәнстан, Белоруссия, Казахстан, Кыргызстан, Молдова, Таҗикстан, Төркмәнстан, Үзбәкстан һәм Украинадан кунаклар көтәләр...

**Сөембикә** http:// syuyumbike.ru/index.php/news/yanalyklar/en-kazanda-bdb-illre-sport-uennary-uzachak

**Җәен Казанда БДБ илләре спорт уеннары узачак**

Быелдан башлап БДБ илләренең спорт уеннары үтә башлый. Ул ике елга бер тапкыр узачак. Аны Россия башлап җибәрә. Уеннарны 20-27 августта Казан кабул итә. Башкалага 11 илдән 2500 спортчы килер дип көтелә. Алар 21 спорт төре буенча көч сынашачак. Спортчылар – яшьләр. 14-23 яшьлек егет-кызлар үзләрен сыный. «Шул рәвешле Олимпия уеннарына алмашчылар әзерләү мөмкинлеге дә бу», – дип белдерде Хәлил Шәйхетдинов. Министр урынбасары әйтүенчә, хәзерге вакытта Татарстаннан 38 спортчы киңәйтелгән исемлектә. Аларның Россия җыелма командасына керү мөмкинлеге бар. Ачылу һәм ябылу тантаналары Баскет-холлда узачак. Уеннар кысаларында милли һәм олимпиягә кермәгән спорт төрләре буенча бөтенроосия фестиваль үткәрү планлаштырыла…

**Татар-информ** https://tatar-inform.tatar/news/sport/21-01-2020/h-lil-sh-yhetdinov-bdb-ill-re-uennaryna-ni-chen-kazan-saylanganyn-a-latty-5717463

**Хәлил Шәйхетдинов БДБ илләре уеннарына ни өчен Казан сайланганын аңлатты**

Аның сүзләренчә, уеннар Татарстанның 100 еллыгына да багышлана.

(Казан, 21 гыйнвар, "Татар-информ", Гөлнар Гарифуллина). 20-27 августта Казанда Бәйсез дәүләтләр берлеге илләре уеннары узачак. Татарстанның спорт министрының беренче урынбасары Хәлил Шәйхетдинов ТР Министрлар Кабинетында брифингта ярышларны уздыру өчен Казан сайлану сәбәбен аңлатты.

"Без БДБ илләре уеннары уздыру хокукын яулау белән горурланабыз. Беренчедән, Җәйге Универсиада, Судагы спорт төрләре буенча дөнья чемпионаты Казанны танытырга мөмкинлек биргәндер. Казанда бөтен спорт корылмалары әзер, өстәмә чыгымнар кирәкми. Казанны оештыру сәләте белән таныттык. Шуңа күрә бик теләп безгә тапшырдылар. Бу Татарстанның 100 еллыгына да багышлана", - диде Хәлил Шәйхетдинов.
Аның сүзләренчә, бу уеннар Татарстанны тагы да таныту өчен әһәмиятле...

**Шәһри Казан** http://shahrikazan.ru/news/kyiskacha-ya%D2%A3alyiklar/2020-elda-kazanda-berenche-tapkyr-bdb-illre-uennary-tchk

**2020 елда Казанда беренче тапкыр БДБ илләре уеннары үтәчәк**

2020 елның 20-27 августында тарихта беренче тапкыр Казанда БДБ илләре уеннары узачак, дип хәбәр итә Казан мэриясе сайты. 19 спорт төре буенча ярышлар Татарстан башкаласының 11 объектында оештырыла. Алар арасында Су спорт төрләре сарае, «Ак Барс» көрәш сарае, Пляж спорт төрләре үзәге, «Мирас» спорт комплексы, Бокс һәм өстәл теннисы үзәге, «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәге, Спорт сарае һәм Үзәк стадион булачак...